КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 март г.Казань № 312

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 август, 914 нче карары белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә урнаштыруның модульле стационар булмаган чараларын булдыруга җәмәгать инициативаларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә урнаштыруның модульле стационар булмаган чараларын булдыруга җәмәгать инициативаларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 26 август, 914 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 17 декабрь, 1362 нче кары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган юридик затларга һәм индивидуаль эшкуарларга Татарстан Республикасы территориясендә урнаштыруның модульле стационар булмаган чараларын булдыруга җәмәгать инициативаларын гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарының бер өлешен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«юридик затлар чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмау. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;»;

әлеге Тәртипнең 5 нче кушымтасының 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компаниясе) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булып тормый.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры А.В.Песошин